**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Өркеш авыл җирлеге Башлыгы**

# КАРАРЫ

**5 ноябрь 2024 ел** **№ 12**

**«Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены уткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 21 ноябренә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын уткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Өркеш авылы, Тау асты урамы, 71А нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчете йортыда уткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар (курсантлар), I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр; 18 яшькә кадәрге балаларын тәрбияләүче ялгыз әниләр ,80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм Өркеш авылында технадзорны гамәлгә ашыру; энергияне саклый торган лампаларны сатып алу, урнаштыру Өркеш авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар һәм башка төр урамнарны яктырту, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру);

-су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау(су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын ремонтлау, тоту, материаллар сатып алу, урнаштыру һәм китерү, су күтәрү манараларын, Өркеш авылының Тау асты урамындагы артезиан скважинасы өчен насослар ,килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән Өркеш авылының Тау асты урамында артезиан скважиналарын куллануга лицензия алу өчен документлар пакетын һәм лаборатория тикшеренүләрен әзерләү буенча чаралар);

- коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү(коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү

буенча башка эш төрләре, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм Өркеш авылында технадзорны гамәлгә ашыру);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Өркеш авылының Тау асты урамында янгын гидрантларын һәм комплектлаучы детальләрне сатып алу һәм урнаштыру ,килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру);

- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (һәйкәлләр территорияләрен төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм Өркеш авылында технадзорны гамәлгә ашыру);

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Өркеш авылының ташлы һәм асфальт түшәлгән юлларын төзү, төзекләндерү, Өркеш авылының урам-юл челтәрен карап тоту, җәйге вакытта территорияне кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, ягулык-майлау материаллары җитештерү һәм килешүгә шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру);

-торак пункт территориясен төзекләндерү (спорт мәйданчыкларын төзү, ремонтлау, аларга якын территорияләрне төзекләндерү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру)

-традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймаларны төзү, төзекләндерү (зират территориясен төзекләндерү,ремонтлау, материал сатып алу һәм урнаштыру, койманы ремонтлау, инвентарь сатып алу, Өркеш авылының Тау асты урамындагы зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Өркеш авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

4.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Өркеш авыл җирлеге башлыгы: А.Ш.Әгъләмова